**Сәхнәләштерелгән уеннар аша  бәйләнешле сөйләм теле үстерү**

Гарипова Алсу Фаридовна

МБДОУ Алан балалар бакчасы

Теләче муниципаль районы,

Сагитова Диляра Василевна

МБДОУ – Лесной балалар бакчасы

Теләче муниципаль районы

***Проект*** : *“ Сәхнәләштерелгән уеннар аша бәйләнешле сөйләм теле үстерү”*

***Проектның актуальлеге***

Нәниләрне дөрес итеп сөйләшергә, үз фикерләрен дөрес итеп әйтә белергә өйрәтү, аларның сүз байлыкларын арттыру – балалар бакчасының төп бурычларыннан берсе булып тора. Чөнки тел киләчәктә баланың барлык фәннәр буенча белем алуына юл ача, аның фикер йөртү сәләтен үстерә һәм акыл үсешенә уңай йогынты ясый. Сөйләмнең үсүе иң беренче чиратта сүзлек запасының ни дәрәҗәдә бай булуыннан тора. Балаларның сүзлек запасын тулыландыру, бәйләнешле сөйләмне үстерү һәм грамматик яктан дөрес сөйләшүләренә ирешү, аларның шәхес буларак та үсүләрен кайгырту ул. Баланы сөйләргә өйрәтү – аның бәйләнешле сөйләмен булдыру дигән дигән сүз.

Бәйләнешле сөйләм үстерү сөйләмнең ике формасын

– диалогик һәм монологик сөйләмен үстерүне күздә тота.

Диалогик сөйләм үстерүдә сорау-җавап формасы, балаларның үзләренең сорау бирә,

бер-берсенә мөрәҗәгать итә белүе – иң отышлы формалар. Балаларның кечкенә хикәяләр-не мөстәкыйль төзи белүе монологик сөйләм барлыкка килүдә мөһим күрсәткеч булып тора.

Баланың сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен- үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур. Акыл үсеше белән сөйләм теленең үсеше нык бәйләнгән. Персонажлар сөйләмен сәнгатьле итеп сөйләү өстендә эшләгәндә, баланың сүз байлыгы арта, аваз культурасы, интонацияле сөйләү тәрбияләнә. Башкарылачак роль баланы чиста, аңлашылырлык итеп сөйләвен таләп итә. Сәхнәләштерелгән уеннар барышында, бала персонажлар өчен кайгырта, үзен алар урынына куя, булышу ысулларын таба, яхшылык һәм явызлыкка үзенең карашын

күрсәтә. Баланы төрле яктан үстерә Сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү барышында, сизелмичә баланың сүз байлыгы арта, бала чиста, дөрес, аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәнә. Сүзлек формалаша- яңа сүзләр белән баетыла. Әкиятне укып бетергәч, балаларга нинди дә булса җөмләне тәмамларга, кабатларга, эчтәлеген сөйләргә тәкъдим ителә. Аннан кечкенә хикәяләр алына. Әкренләп монологик сойләм генә түгел, ә диалогик сөйләм дә үсә. Аваз культурасы өстендә эшләнелә. Бала күп нәрсәне исендә калдыра. Аның хәтере үсә. Рольне уйный- уйный, бала әкият дөньясына кереп китә, татар телен истә калдыру җиңеләя. Сәхнәләштерү эшчәнлеге күрсәтүенчә, бала ялгышырга мөмкин, ә менә әкият герое ялгышырга тиеш түгел. Шуңа күрә балалар әкият уйнаганда, сүзләрен 2–3 мәртәбә тырышыбрак өйрәнәләр. Аларның бу шөгыльләрдән соң хәтерләре яхшыра.

Сәхнәләштерү уеннарын үзләштерү ярдәмендә балаларның интонацияләре яхшыра, башка катнашучылар белән аралашу осталыклары арта, килешү, конфликтлы ситуацияләрне чишә белү мөмкинлекләре туа. Балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үсә.

***Проектның максаты***: Балаларның  диалогик һәм монологик бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү

***Бурычлар***:

- сүз байлыгын үстерү, активлаштыру;

- кара-каршы сөйләшү күнекмәләре бирү;

- монологик, диалогик сөйләм формалаштыру;

- иптәшләре белән үзара тыныч,ягымлы итеп сөйләшә белергә,башкалар сөйләгәнне игътибар белән тыңларга өйрәтү;

- персонажларны кичерешләренә бәйле рәвештә,интонацияне үзгәртеп,кирәкле урында пауза ясап сөйләргә өйрәтү

***Проектның төре*:** иҗади сөйләм үстерү

***Проектта катнашучылар***: балалар, ата – аналар, тәрбияче

***Проектны гамәлгә ашыру вакыты***: сентябрь-май.

**Проектның этаплары:**

***<u>Әзерлек этабы:</u>***

1. Проектның темасын сайлау.

2. Проблема кую.

3. Проект буенча материал җыю.

4. Әти - әниләр өчен информацион папка ясау.

6. Әти - әниләр “почмагын” тулыландыру.

8. Әкиятләр өчен битлекләр әзерләү.

***<u>Төп этап:</u>***

1. Әңгәмә уздыру.

2. Табышмаклар әйтешү.

3. Әкиятләр уку һәм аны сәхнәләштерү.

4. Шигырь ятлау.

5. Төрле уеннар уйнау.

6. Эндәш ятлау.

7. Татар телендә мультфильм карау.

8. Рәсем ясау.

9. Йомгаклау.

**Көтелгән нәтиҗәләр**

1. Балаларның сүз байлыгы арта, активлаша,бәйләнешле сөйләмнәре үсә;
2. Авазларны дөрес әйтү күнекмәсе була;
3. Монологик, диалогик сөйләм формалаша;
4. Башкалар сөйләгәнне игътибар белән тыңларга өйрәнәләр;
5. Интонацияне үзгәртеп,кирәкле урында пауза ясап сөйләү формалаша

***Кулланылган әдәбият.***

1.“Туган телдә сөйләшәбез”5-7 яшь, - Методик кулланма. З.М. Зарипова, Казан. 2012

2.”Балачак аланы” хрестоматия К.В.Закирова ,Казан:РИЦ,2011

3.”Уйныйк әле, балалар”Өченче китап “М.Ф.Кашапова ,Казан 2017

4.”Балалар бакчасында түгәрәкләр”методик ярдәмлек Т.Р.Шакирова ,Казан 2016

Халкыбыз гасырлар төпкеленнән килә торган иң күркәм сыйфатларның берсе - өлкәннәргә ихтирам,ата-анага хөрмәт,кардәш-ыру белән тыгыз аралашып,ярдәмләшеп яшәүне бик мөһим санаган.Яшәеш барышында бу сыйфатлар тирән эчтәлекле әхлакый нормалар,милләт өчен әһәмиятле таләпләр булып формалашкан:”Ата-анаңны,өлкәннәрне хөрмәтләү-фарыз”,”Олыларны олылау-фарыз”,”Җиде бабаңны белү – фарыз”, ”Туганнарың белән аралашмау – хурлык” һәм башкалар.

Гаиләдәге һәр өлкән кешенең үз урыны булган.Әби белән бабай үз балалары өчен дә,оныклары өчен дә үрнәк саналганнар.Аларның тормыш тәҗрибәсе ,үтемле киңәшләре гаять күптөрле һәм четерекле мәсьәләләрне уңышлы чишәргә мөмкинлек биргән.

Балаларны туган халкыбызның үткәне ,әби-бабаларыбызның гореф-гадәтләре,гаилә шәҗәрәсе ,йолалары һәм бүгенге тормыш белән таныштыру зарур.

Мәктәпкәчә чор – патриотик хисләр, шул исәптән эти-әни ,әби-бабай, туганнарга, ягъни гаилә әһелләренә мәхәббәт тәрбияләү өчен иң сензитив, уңай период булып санала.Шушы чорда иң әһәмиятле әхлакый сыйфатлар формалаша.

Без үзгәрешләр заманында яшибез.Тупланган тәҗрибәләр югала бара, интернет һәм телевидение, урам йогынтысы балаларның аңына , рухына әдәпсезлек үрнәкләрен сеңдергән чорда мәктәпкәчә белем бирү учреждения-сендә нәниләргә халкыбыз хәзинәләре нигезендә ата-аналарга мәхәббәт тәрбияләүгә аеруча зур игътибар бирелергә тиеш.Балаларны туган халкыбызның үткәне,гореф-гадәтләр, гаилә шәҗәрәсе,йолалары һәм бүгенге тормыш белән таныштыру зарур.Шул уйдан балалар бакчасында “Гаилә белеме”(“Семьеведение”) кертелә башлады.Без аны көндәлек режим вакытларында ,атнага бер тапкыр үткәрәбез.Гаилә белеме буенча “Гаилә – бәхетнең нигезе” проектын эшләдек.